**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Төги авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 36** **«27» июль 2021 ел**

**«Төги авыл җирлегендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 15 маендагы 135 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Конституциясенә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау турында» 719 номерлы карарына, "Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында" 2020 елның 06 февралендәге 103 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Төги авыл җирлегендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 15 маендагы 135 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының “Авыл җирлекләре” бүлегендә урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Т.В.Попова**